ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

25 04 2022 г. № 241

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Агач һәм куакларны кисү, ябалдашларын формалаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны бетерү өчен карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 26 июлендәге 679 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Агач һәм куакларны кисү, ябалдашларын формалаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны бетерү өчен карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 26 июлендәге 679 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.С. Игътисамовка йөкләргә»;

1.2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 июлендәге 679 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисү, ябалдашларын формалаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны бетерү өчен карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.2. өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Регламентка 1, 3, 7 нче кушымталар Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының вәкаләтле заты тарафыннан имзаланырга тиеш.»;

2.5.7 өлешнең 3 пунктындагы «г» пунктчасында «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен «вәкаләтле зат» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.3 пунктның беренче абзацында «килештерү һәм имзалау» сүзләрен «килештерү һәм имзалауны тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга, «Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5.3 пунктның 3, 4 абзацларында «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен «Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 1 нче кушымтада «район Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен «Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 7 нче кушымтада «Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р С. Игътисамовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874